**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Әгерҗе авыл җирлеге Советы карары**

Әгерҗе авылы № 182-85 «18» август 2020 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге Советы карары белән расланган 2012 елның 29.10. 50 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының « Әгерҗе авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында (2014 елның 04.04. 86 номерлы, 2014 елның 15.08. 100 номерлы, 2017 елның 11.09. 64-29 номерлы, 2019 елның 15.02. 129-61 номерлы карарлар редакциясендә)

2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Әгерҗе авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Әгерҗе авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә тулаем төзекләндерү объектларын чисталыкта һәм тәртиптә тотуга бердәм таләпләр билгеләү максатында,

Әгерҗе авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге Советы карары белән расланган 2012 елның 29.10. 50 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының « Әгерҗе авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә (2014 елның 04.04. 86 номерлы, 2014 елның 15.08. 100 номерлы, 2017 елның 11.09. 64-29 номерлы, 2019 елның 15.02. 129-61 номерлы карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.2. пунктның өченче абзацында «каты көнкүреш калдыклары» сүзләрен «каты коммуналь калдыклар» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 1.3. пунктның унынчы абзацында «каты көнкүреш калдыклары» сүзләрен «каты коммуналь калдыклар» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. 2.7.пунктта «каты көнкүреш калдыклары» сүзләрен «каты коммуналь калдыклар» сүзләренә алмаштырырга.

1.4. 2.10.3 – 2.11.2, 2.11.4 пунктларда «каты көнкүреш калдыклары» сүзләрен «каты коммуналь калдыклар» сүзләренә, «ТБО» аббревиатурасын «ТКО» аббревиатурасына алмаштырырга.

1.5. Түбәндәге эчтәлекле 2.11.7 пункт белән тулыландырырга:

«2.11.7. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Әгерҗе авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыклар туплау урыннарын (мәйданчыкларын) төзекләндерү һәм аларның реестрын алып бару кагыйдәләре авыл җирлеге Башкарма комитетының норматив хокукый акты белән билгеләнә.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми

порталында» түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: http//aznakayevo.tatar.ru. веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис: Н.Н.Хәсәнов